**КАБИНЕТ МИНИСТРОВ РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН**

**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ**

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ**

**КАРАР**

2015 ел, 12 март

№ 149

г. Казань

Татарстан Республикасында шәһәр төзелешен проектлау нормативлары реестрын алып бару тәртибен раслау турында

Россия Федерациясе Шәһәр төзелеше кодексының 29.1 статьясын һәм «Татарстан Республикасында шәһәр төзелеше эшчәнлеге турында» 2010 ел, 25 декабрь, ТРЗ-98 нче Татарстан Республикасы Законының 14.1 статьясын тормышка ашыру максатларында, Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:

Татарстан Республикасында шәһәр төзелешен проектлау нормативлары реестрын алып бару тәртибен (карарга теркәлә) расларга.

Татарстан Республикасы
Премьер-министры И.Ш.Халиков

F:\KARAR\2015\149.doc

Татарстан Республикасы
Министрлар Кабинетының
2015 ел, 12 март, 149 нчы
карары белән расланды

# Татарстан Республикасында шәһәр төзелешен проектлау нормативлары реестрын алып бару тәртибе

1. Бу Татарстан Республикасында шәһәр төзелешен проектлау нормативлары реестрын алып бару тәртибе (алга таба - Тәртип) Россия Федерациясе Шәһәр төзелеше кодексының 29.1 статьясы һәм «Татарстан Республикасында шәһәр төзелеше эшчәнлеге турында» 2010 ел, 25 декабрь, ТРЗ-98 нче Татарстан Республикасы Законының 14.1 статьясы нигезендә эшләнде һәм төбәк әһәмиятендәге объектлар һәм җирле әһәмияттәге объектлар төрләре буенча Татарстан Республикасында шәһәр төзелешен проектлау нормативлары реестрын (алга таба – Реестр) алып баруга һәм тотуга карата таләпләр билгели.

2. Реестр шәһәр төзелешен проектлауның төбәк һәм җирле нормативларын системалаштыруны тәэмин итү, Реестрдан шәһәр төзелешен проектлауның төбәк һәм җирле нормативлары турында Россия Федерациясе дәүләт хакимияте органнарының, Татарстан Республикасы дәүләт хакимияте органнарының һәм җирле үзидарә органнарының, физик һәм юридик затларның мәгълүматлар алуы өчен шартлар тудыру максатларында алып барыла.

3. Реестр түбәндәгеләрдән торучы шәһәр төзелешен проектлау нормативларын үз эченә ала:

1) шәһәр төзелешен проектлауның төбәк нормативларыннан;

2) түбәндәгеләрне үз эченә алган шәһәр төзелешен проектлауның җирле нормативларыннан:

а) муниципаль район шәһәр төзелешен проектлау нормативларыннан;

б) җирлек шәһәр төзелешен проектлау нормативларыннан;

в) шәһәр округы шәһәр төзелешен проектлау нормативларыннан.

4. Реестрга түбәндәгеләрне үз эченә ала торган шәһәр төзелешен проектлауның төбәк һәм җирле нормативлары турында мәгълүматлар кертелә:

Татарстан Республикасы норматив хокук актларының тулы исемен һәм реквизитларын, шәһәр төзелешен проектлауның төбәк һәм җирле нормативларын яки аларга кертелгән үзгәрешләрне раслау турындагы муниципаль норматив хокук актларын; аларны рәсми бастырып чыгару чыганакларын;

шәһәр төзелешен проектлауның төбәк һәм җирле нормативларын яки аларга кертелгән үзгәрешләрне раслау турындагы Татарстан Республикасы норматив хокук актлары, муниципаль норматив хокук актлары текстларын;

документны әзерләгән оешма турындагы мәгълүматларны;

төбәк әһәмиятендәге объектлар һәм җирле әһәмияттәге объектлар төрләре турындагы мәгълүматларны, аларны Реестрда теркәү датасын.

5. Җирле үзидарә органнары шәһәр төзелешен проектлауның җирле нормативларын яки аларга кертелгән үзгәрешләрне раслаганнан соң эш көннәрендә исәпләнә торган биш көн эчендә аларны раслау турындагы акт күчермәсен һәм бу Тәртипнең 4 нче пунктында күрсәтелгән мәгълүматларны Реестрга кертү өчен Татарстан Республикасының Төзелеш, архитектура һәм торак-коммуналь хуҗалык министрлыгына (алга таба – Министрлык) кертә. Документлар электрон рәвештә һәм кәгазь чыганакта тапшырыла.

6. Министрлык бу Тәрипнең 5 нче пунктында күрсәтелгән документлар кергәннән соң эш көннәрендә исәпләнә торган өч көн эчендә мәгълүматны Реестрга кертә.

7. Реестр Министрлыкның «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендәге сайтында электрон рәвештә алып барыла.

8. Бу Тәртипнең үтәлешен тикшерүдә тотуны Татарстан Республикасының Төзелеш, архитектура һәм торак-коммуналь хуҗалык министрлыгына йөкләргә.

---

F:\KARAR\2015\149-1.doc